**МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.07.2024 № 262-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 12 февралендәге 88-осн номерлы боерыгы белән расланган Нурлат урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Нурлат урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын раслау турында» 2019 елның 12 февралендәге 88-осн номерлы боерыгы (16.04.2020 ел, №311-осн, 02.12.2020 ел, №833-осн, 17.01.2022 ел, №39-осн, 05.12.2023 ел, №552-осн боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Кәләй урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары И.Н.Зариповка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 16 июлендәге 262-осн номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 12 февралендәге 88-осн номерлы боерыгы белән расланган Нурлат урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.2 бүлекнең 5 нче таблицасына түбәндәге эчтәлекле Искәрмә өстәргә:

«Искәрмә.

1. Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә урнашкан урманнардан файдалануның барлык рөхсәт ителгән төрләре режимы тиешле махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы нигезләмәләр белән билгеләнә (РФ Урман кодексының 112 статьясы).

2. Урманнарда агач материалы әзерләү Россия Федерациясе Урман кодексының 23.1, 23.2, 23.3, 23.5, 29, 29.1, 30, 111-115 статьялары, РФ Табигать ресурслары министрлыгының «Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда агач материалы әзерләү кагыйдәләрен һәм агач материалы әзерләү үзенчәлекләрен раслау турында» 2020 елның 1 декабрендәге 993 номерлы боерыгы, Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Урманнарны карау кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 534 номерлы боерыгы нигезендә рөхсәт ителә.

3. Чәер әзерләү РФ Урман кодексының 31 статьясы һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 911 номерлы боерыгы нигезендә агач материалы әзерләү өчен билгеләнгән урманнарда гамәлгә ашырыла. Чәерне зарарлы организмнар булган урыннарда, урман янгыннары, зарарлы организмнар һәм башка тискәре факторлар тәэсирендә зарарланган һәм көчсезләнгән утыртмаларда; агач материалы әзерләү өчен өлгергән һәм картайган утыртмаларны тоташ яки сайланма кисү рөхсәт ителмәгән урман утыртмаларында, урман-орлык плантацияләренең даими урман-орлык кишәрлекләрендә, генетик резерватларда әзерләү рөхсәт ителми. Плюс агачларына, орлыклык агачларга, орлыклык агачлар төркемнәренә һәм полосаларына кирт салу рөхсәт ителми.

4. Урманнарда агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю РФ Урман кодексының 32 статьясы һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 496 номерлы боерыгы нигезендә рөхсәт ителә.

5. Урманнарда азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үсемлекләрен җыю РФ Урман кодексының 35 статьясы һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үсемлекләрен җыю кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 494 номерлы боерыгы нигезендә рөхсәт ителә.

6. Урманнарда аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру РФ Урман кодексының 36 статьясы нигезендә рөхсәт ителә, РФ Урман кодексының 114 статьясында һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 12 декабрендәге 661 номерлы боерыгында каралган очраклар искәрмә булып тора.

7. Урманнарда авыл хуҗалыгын алып бару РФ Урман кодексының 38 статьясы һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен һәм урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яисә билгеләмичә авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 2 июлендәге 408 номерлы боерыгы нигезендә рөхсәт ителә, РФ Урман кодексының 114 статьясында каралган очраклар искәрмә булып тора.

8. Урманнарда фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру РФ Урман кодексының 40 статьясы һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 487 номерлы боерыгы нигезендә рөхсәт ителә.

9. Урманнарда рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру РФ Урман кодексының 41 статьясы һәм Россия Табигать министрлыгының «Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 908 номерлы боерыгы нигезендә рөхсәт ителә.

10. Урманнарда урман плантацияләре төзү РФ Урман кодексының 42 статьясы нигезендә рөхсәт ителә.

11. Урманнарда җиләк-җимешле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү РФ Урман кодексының 39 статьясы һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Җиләк-җимешле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 497 номерлы боерыгы нигезендә рөхсәт ителә.

12. Урманнарда урман питомникларын төзү һәм алардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 39.1 статьясы һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Урман питомникларын төзү һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 12 октябрендәге 737 номерлы боерыгы нигезендә рөхсәт ителә.

13. Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, эзләү һәм файдалы казылмалар чыгаруны гамәлгә ашыру өчен файдалану РФ Урман кодексының 43 статьясы һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, эзләү һәм файдалы казылмалар чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану тәртибен һәм, җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру максатларында, урман кишәрлеге бирелмичә, сервитут билгеләп яки билгеләмичә урманнардан файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 7 июлендәге 417 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла, яшел зоналар, урман паркы, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү тыела торган зоналар искәрмә булып тора (РФ Урман кодексының 114 статьясы).

14. Урманнарда сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портларын төзү һәм аларның территорияләрен киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү РФ Урман кодексының 44 статьясы нигезендә рөхсәт ителә. Гидротехник корылмалар төзүдән тыш, урман паркы зоналарында һәм яшел зоналарда капиталь төзелеш объектлары төзү рөхсәт ителми (РФ Урман кодексының 114 статьясы). маддәсе).

15. Урманнарда линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү РФ Урман кодексының 21, 21.1, 45 статьялары һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен һәм урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә, линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 10 июлендәге 434 номерлы боерыгы нигезендә рөхсәт ителә, РФ Урман кодексының 114 статьясының 4 һәм 5 өлешләрендә каралган чикләүләрдән тыш.

16. Урманнарда дини эшчәнлек алып бару РФ Урман кодексының 47 статьясы һәм 125-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә рөхсәт ителә.

17. Урманнардан файдалану, саклау, яклау, аларны торгызу әлеге урманнар урнашкан җирләрнең максатчан билгеләнеше нигезендә гамәлгә ашырыла. Урманнардан файдалану төрләре, аларның максатчан билгеләнешенә карамастан, махсус сакланылучы табигать территорияләре турында нигезләмәләр, урман фонды җирләрендә урманнардан файдалану режимын билгели торган башка документлар белән эшләнгән яки кабул ителә торган норматив-хокукый актлар белән чикләнергә мөмкин.»;

2.18 бүлекнең 2.18.3 бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«РФ Урман кодексының 631 статьясының 6 өлеше нигезендә, РФ Урман кодексының 631 статьясының 1, 2 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән затлар, башка федераль законнарда башкача билгеләнмәсә, РФ Урман кодексының 631 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән очракта урман утыртмаларын кискәннән соң яки РФ Урман кодексының 631 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән очракта,

җирләрне урман фонды җирләреннән башка категория җирләренә күчергәч өч елдан соңга калмыйча, урман питомникларында үстерелгән үсентеләрне, төп урман барлыкка китерүче токымнарның чәчкеннәрен утыртуны һәм утырту мизгеленнән башлап өч ел эчендә урманның төп агач токымнарының урман үсемлекләрен агротехник карап тотуны тәэмин итәләр.

Урманнарны торгызу кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектлары территориясендә урманнарны ясалма һәм катнаш торгызу мәйданнарының бер өлеше, дала, ярымчүлләр, чүлләр зоналарыннан тыш, ябык тамыр системалы чәчкеннәр һәм (яисә) үсентеләр утырту юлы белән башкарыла (2025 елның 1 мартына кадәр кимендә 20%, 2025 елның 1 мартыннан кимендә 30%).».